КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.01.2025 № 4-П

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2023 нче елның 31 нче октябренең 716-П номерлы боерыгы белән расланган Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы Комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 маендагы 393 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы 2024 елның 10 октябренә караган 1360 номерлы карары кабул итүелүгә бәйле рәвештә боерам:

1. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2023 нче елның 31 нче октяберендәге 716-П номерлы «Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты администрацияли торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану" турындагы боерыгы белән расланган (2024 нче елның 10 нчы сентябрендәге 451-П боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитеты тарафыннан карарлар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пунктта:

«а» пунктчасында «хисаплылыктан өземтә» сүзләрен «белешмә» сүзенә алмаштырырга;

«б» пунктчасында «, Россия Федерациясе Бюджет кодексының $160^1$ статьясы нигезендә бюджетка түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү буенча бюджет керемнәре администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентында каралган» сүзләрен өстәргә;

«в» пунктчасында:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«амнистия турында акт яисә штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгәннәргә карата ярлыкау акты яисә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалта торган суд акты, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә (Тәртипнең 2 пунктындагы «г» пунктчасында күрсәтелгән очракта);»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гражданның судтан тыш банкротлыгы процедурасын тәмамлау турында банкротлык турында белешмәләрнең бердәм федераль реестрыннан белешмәләр булган документ (Тәртипнең 2 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән очракта).».

2. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис И.Н. Гущин